РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 21 » 08 2023 г. №1254

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 25.01.2022 № 43 карары белән расланган, Торак урыннарына мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 28.02.2022 ел, 175 номерлы карары, "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 25.01.2022 № 43 карары белән расланган, Торак урыннарына мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтү күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Административ регламентның 11 абзацы 3.3.2.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Формат-логик тикшерү Бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә орган (оешма) билгеләгән таләпләр нигезендә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан соратуның электрон формасындагы һәр кырын тутыру процессында башкарыла. Бердәм

портал тарафыннан дөрес тутырылмаган электрон формадагы сорату кыры ачыкланганда, гариза бирүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында турыдан-туры соратуның электрон формасындагы мәгълүмати хәбәр аша хәбәр ителә.».

1.2. Административ регламентның 2.6.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6.1. Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында түбәндәгеләр алына:

1) күчемсез мөлкәтнең булган объектларына аерым затның хокуклары турында БДКМРнан өземтә - Дәүләт теркәвенең, кадастр һәм картография федераль хезмәте (Росреестр);

2) күчемсез милек объектына ЕГРНнан өземтә - Дәүләт теркәвенең, кадастр һәм картография федераль хезмәте (Росреестр);

3) гражданлык хәле актларын теркәүнең бердәм дәүләт реестрыннан үлемне дәүләт теркәве турында белешмәләр - Россия Федераль салым хезмәте;

4) гражданлык хәле актлары язмаларының Бердәм дәүләт реестрыннан тууны дәүләт теркәве турында мәгълүматлар - Россия Федераль салым хезмәте;

5) гражданлык хәле актлары язмаларының Бердәм дәүләт реестрыннан никахны теркәү (өзү) турында мәгълүматлар - Россия Федераль салым хезмәте;

6) яшәү урыны һәм килү урыны буенча теркәү исәбе турында белешмәләр - Россия Эчке эшләр министрлыгы;

7) торак бинада яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар санын раслый торган белешмәләр - күпфатирлы йортның идарәче оешмасы йә исәп-хисап үзәге;

8) граждан һәм аның гаилә әгъзалары яши торган торак урыннан (шартнамә, ордер, торак урын бирү турында карар һәм башка документлар) файдалану хокукын раслый торган документлар - җирле үзидарә органы;

9) торак йортны (торак урынны) яшәү өчен яраксыз дип тану турында карар - федераль башкарма хакимият органы, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы, җирле үзидарә органы;

10) социаль түләүләрне алу турында белешмәләр - Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды;

11) 2-НДФЛ формасы буенча физик затның керемнәре турында белешмәләр - Россия Федераль салым хезмәте;

12) индивидуаль эшкуар булган затның 3-НДФЛ формасы буенча керемнәре турында белешмәләре - Россия ФСХ ;

13) гражданнарның федераль законда, Россия Федерациясе Президенты Указында яисә Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән башка торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алу хокукы булган категориягә карата мөнәсәбәтен раслый торган документлар - вәкаләтле орган;

14) физик затның салым органында исәпкә кую турындагы белешмәләр (ИНН) - Россия ФСХ ;

15) индивидуаль шәхси счет иминият номеры турында белешмәләр (СНИЛС) - Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды:

16) транспорт чарасы булу турында белешмәләр - Россия Эчке эшләр министрлыгы, Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы;

17) гариза законлы вәкил тарафыннан бирелгән очракта мөрәҗәгать итүченең законлы вәкиле вәкаләтләрен раслый торган документ (Россия Федерациясе гражданлык хәле актларын теркәү органнары тарафыннан бирелгән туу турында таныклык яисә Россия Федерациясе законнары нигезендә опека һәм попечительлек органнары тарафыннан бирелгән документ) - Россия Федераль салым хезмәте, Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фонды;

18) фамилия-исем төркеменең, туу датасының, җенесенең һәм СНИЛСның туры килүен тикшерү - Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды;

19) паспортының чынлыгы турында белешмәләр - Россия Эчке эшләр министрлыгы;

20) ышанычнамәне бирү факты һәм эчтәлеге турында белешмәләр - нотариатның бердәм мәгълүмат системасы.

Мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге регламентның 2.5.6 пункты белән билгеләнгән. Мөрәҗәгать итүчедән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагындагы югарыда санап үтелгән документларны таләп итү тыела.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм Порталы составында «Рәсми Татарстан» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны инфраструктура үсеше буенча Башкарма комитет җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С. П. Самонина